**Каралды**
**Татар теле һәм әдәбияты укытучыларының**
**методик берләшмәсе җитәкчесе**
**__________ Рамазанова Р.Н.**
**Беркетмә № 1**
**25нче август 2017нче ел**

**Килешенде**
**Уку-укыту эшләре буенча**
**директор урынбасары**
**__________ Г.Т.Исмагилова**
**28нче август 2017нче ел**

**Раслыйм**
**Мәктәп директоры**
**________ Г.Т.Сабирзянова**
**Боерык № 71**
**28нче август 2017нче ел**

***ЭШ ПРОГРАММАСЫ***

## Татарстан Республикасы Сарман районының муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе “Сарман урта гомуми белем бирү мәктәбе”

## Татар теле, 8нче Б сыйныфы

## Һәм “Каташ-Каран төп гомуми белем бирү” филиалы Татар теле, 8нче сыйныф

## Кәримова Резедә Рәшит кызы

**Педсовет утырышында каралды**
**Беркетмә №1, 28 нче август 2017нче ел**

**2017-2018нче уку елы**

**АННОТАЦИЯ**

Эш программасы Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан расланган "Татар телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теленнән программага нигезләнеп төзелде (авторы: Зәкиев М.З., Максимов Н.В. һ.б. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2011). 8 нче сыйныфның укыту планында татар телен укытуга атнасына 3 сәгать вакыт каралган. (барлыгы 105 дәрес).

**Дәреслек:** Татар теле. 8 сыйныф: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы/ М.З.Зәкиев, Н.В.Максимов. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2015.

# Аңлатма язуы

**Эш программасы түбәндәге норматив документларга нигезләнеп төзелде:**

1. Россия Федерациясенең "Мәгариф турында" Федераль законы (№273, 12.12.2012 ел).
2. Татарстан Республикасының "Мәгариф турында" Законы (№68, 22.07.2013 ел):
   - 7нче маддә – Татарстан Республикасында уку-укытуның үсеш программалары,
   - 8нче маддә – уку-укыту теле.
3. Татар теленнән гомуми белем бирүнең дәүләт стандарты. ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы. – Казан, 2008.
4. Татар телендә урта гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теленнән программа: 5-11 нче сыйныфлар. – Казан: Мәгариф, 2010.
5. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан расланган "Татар телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теленнән программа (авторы: Зәкиев М.З., Максимов Н.В. һ.б. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2011.
6. Сарман муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе " Сарман урта гомуми белем бирү мәктәбе"нең 2017-2018 нче уку елына укыту планы.
7. "Сарман урта гомумбелем бирү" мәктәбенең "Укыту курслары һәм предметларыннан эш программалары төзелеше, аларны эшләү һәм раслау тәртибе турында" турындагы нигезләмәсе.

Укыту планында 8 нче сыйныфта татар телен өйрәнүгә атнага 3 сәгать вакыт бирелә.

Программа материалы 105 сәгатьлек булып, атнага 3 сәгать укыту хисабыннан төзелде. Якынча программада туры һәм кыек сөйләм темасына 12 сәгать каралган. Диктант һәм хаталарны төзәтү эше өчен шул темадан 2 сәгать алдым.

**Искәрмә:** "Сарман урта гомумбелем бирү мәктәбе"муниципаль белем бирү учреждениесенең „Укыту курслары һәм предметларыннан эш программалары төзелеше, аларны эшләү тәртибе турында" гы 29 нчы август 20176 нчы елда педсоветта каралган (беркетмә № 1) һәм мәктәп директоры тарафыннан 2016 нчы елның 29 нчы августында чыккан 109 нчы санлы приказы белән расланган нигезнамәнең 5нче пунктына таянып, дәресләр бәйрәм көннәренә туры килү сәбәпле, 8 нче сыйныфnа дәресләр сәгатьләрне берләштерү исәбенә үтәлә.

Татар теленнән дәүләт стандартында (Казан, 2004) синтетик һәм аналитик иярченле кушма җөмлә темасы каралган. Ә якынча программада бу темага аерым сәгать бирелмәгән. "Иярченле кушма җөмлә" темасында кабатлау өчен бирелгән 6 сәгатьне: 1) синтетик иярчен җөмләләр, 2) синтетик иярчен җөмләләр янында тыныш билгеләре; 3) аналитик иярчен җөмләләр, 4) аналитик иярчен җөмләләр янында тыныш билгеләре; 5) аналитик һәм синтетик иярченле кушма җөмләләрне кабатлау, 6) иярченле кушма җөмләләр синонимлыгы темалары өчен алдым.

“Катлаулы төзелмәләр” бүлегендә, иярченле кушма җөмләләрне гомумиләштереп кабатлау өчен, 8 сәгать каралган. Иярченле кушма җөмләләрне гомумиләштереп кабатлау өчен, 4сәгатьне иярченле кушма җөмләләрне йомгаклаганда, калган 4 сәгатьне “Катлаулы төзелмәләр” бүлегендә алынды.

Якынча программаның бәйләнешле сөйләм үстерү бүлегендә бирелгән 12 сәгать эчендә “Җөмләнең мәгънәсе һәм төзелеше, интонация һәм тыныш билгеләре” темасы да каралган. Бу теманы иярченле кушма җөмләләрд ә(№37) һәм катлаулы төзелмәләрдә (№-№61,68,69,70, 72,74,76,89,101) тыныш билгеләренең куелышын аңлатып бардым.

Соңгы елларда республикада татар теленең куллану даирәсе киңәйде, иҗтимагый функциясе көчәйде. Милләтара мөнәсәбәтләрне якынлаштыручы, җайга салучы чара буларак та аның мөмкинлекләре үсте. Укучыларда **лингвистик** (тел), **аралашу** (коммуникатив), **этнокультура өлкәсенә караган** (культурологик) **компетенцияләр** булдыру татар теленә өйрәтүнең максатын тәшкил итә.

**Лингвистик компетенция** (укуыларның ана телелннән мәгълүматлылыгы) фонемалар, морфемалар, сүз ясалышы, сүзтезмәләр, җөмләләр, җөмлә кисәкләре, лексик һәм грамматик берәмлекләр, лингвистик анализны һ.б. үз эченә ала.

**Аралашу** (коммуникатив) **компетенциясе** ул – башкалар әйткәнне аңлау һәм үз фикереңне белдерү өчен тупланган белем, осталык, күнекмәләр җыелмасы; хәзерге татар теле нормаларына ия булу, сүз байлыгын, сөйләмнең грамматик ягын дөрес итеп үзләштерү; телдән һәм язма формада бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен булдыру һ.б.

**Этнокультура өлкәсенә караган** (культурологик) **компетенция,** ягъни телне милли-мәдәни яссылыкта үзләштерү ул – укучыларны сөйләмгә милли үзенчәлекләрне чагылдырган текстлар белән эшләү, тормыш-көнкүреш, гореф-гадәт үзенчәлекләрен, сынлы сәнгать әсәрләрен, халык авыз иҗаты үрнәкләрен белү, татар сөйләм этикетына ия булу.

## Татар телен укытуның максатлары

- Укучыларда туган телгә хөрмәт тәрбияләү, аның иң зур рухи кыйммәт булуын аңлату.
- Укучыларның сөйләү һәм фикерләү сәләтен үстерү, татар телен тормышның төрле өлкәләрендә иркен куллана алырлык шәхесләр итеп тәрбияләү.
- Кушма җөмлә эчендәге гади җөмләләрне аера белү; диалог, монологтан файдалана белү, тыныш билгеләрен дөрес кую кунекмәләре булдыру. Татар теле, аның төзелеше, кулланылышы турында мәгълүмат бирү; сүз байлыгын арттыру; туры һәм кыек сөйләмле, кушма җөмлә һәм катлаулы төзелмә, алар янында тыныш билгеләре куелышының нормаларын һәм мөмкинлекләрен аңлату, тиешенчә куллана белү күнекмәләре фомалаштыру.
- Сөйләм культурасын тәрбияләү.

## Татар мәктәпләрендә татар теле укытуның төп бурычлары

1. Татар теленең туры һәм кыек сөйләм, кушма җөмлә һәм катлаулы төзелмә, пунктуация бүлекләре буенча эзлекле рәвештә фәнни белем бирү.
2. Сөйләм эшчәнлеге төрләре буенча ныклы күнекмәләр булдыру. Туган телдә матур һәм дөрес аралашырга өйрәтү.
3. Телдән һәм язма сөйләм осталыгы һәм күнекмәләрен камилләштерү, татар теле мөмкинлекләреннән тулысынча файдалана белергә өйрәтү.
4. Татар телен башка фәннәр буенча белем алу чарасы буларак кулланырга өйрәтү күнекмәләре булдыру.
5. Укучыларның логик фикеләү сәләтләрен үстерү.
6. Дәреслек, өстәмә һәм белешмә әдәбият белән эш итү, уку, язу күнекмәләрен камилләштерү.

Укучыларның гомуми грамоталылыгын тикшерү һәм үстерү өчен, төрле характердагы диктантлар, шулай ук сүзлек байлыгын арттыру, бәйләнешле сөйләм үстерү, логик фикерләү дәрәҗәсен камилләштерү максатыннан сочинение һәм изложениеләр яздырыла.

Эш программасы тел белеме тармаклары арасында системалылык һәм эзлеклелек, фәннилек, аңлаешлылык принципларын истә тотып төзелде.

**Белем бирү эчтәлегенең мәҗбүри минимумы коммуникатив компетенция.**

Сөйләм. Телдән һәм язма сөйләм. Диалогик һәм монологик сөйләм. Сөйләм стильләре. Матур әдәбият теле. Телдән һәм язма сөйләмне аеру. Тел берәмлекләрен, аралашуны ситуация үзенчәлекләренә карап сайлый белү. Аралашу өлкәсенә һәм ситуациясенә бәйле рәвештә телдән һәм язма сөйләмне дөрес файдалану.

Текстның темасы, төп фикере һәм төзелеше. Аларның стильләрендә жанр төрлелеге.

Татар әдәби теле һәм нормалары турында төшенчә.

Төрле язма эшләр башкару.

**Лингвистик компетенция.**

Телнең кеше тормышындагы һәм җәмгыятьтә тоткан урыны. Татар теле – ТР дәүләт теле. Татар теле – татар халкының милли теле. Әдәби тел һәм аның нормалары турында төшенчә. Татар теленең үсештә булуы. Структур һәм функциональ үсеш. Тел белеменә караган сүзлекләр һәм алардан файдалану.

**Эш программасының эчтәлеге**

Тематик план, программа материалын 105 сәгатькә бүлеп, атнага 3 сәгать хисабыннан төзелде

| № | Төп темалар | Сәгать | Белем һәм күнекмәләр |
|---|---|---|---|
| 1. | Тел һәм тел гыйлеме. | 1 | Тел гыйлеменең бүлекләрен искә төшерү |
| 2. | Үткәннәрне искә төшерү. Кабатлау. | 3 | Фонетика, морфология бүлеген кабатлау. |
| 3. | Диалог һәм монолог, туры һәм кыек сөйләм. Туры сөйләм, кыек сөйләм. | 9 | Диалог, реплика, туры сөйләм, кыек сөйләм, цитата төшенчәләрен аңлата белү. |
| 4. | Кушма җөмлә турында гомуми төшенчә. Тезмә кушма җөмлә. Теркәгечле һәм теркәгечсез тезмә кушма җөмлә. Теркәгечле һәм теркәгечсез тезмә кушма җөмлә, аларда бәйләүче чаралар, тыныш билгеләре. | 6 | Тезмә кушма җөмләләрне аера белү, синтаксик анализ ясау |
| 5. | Иярченле кушма җөмлә. Төзелеше буенча синтетик, аналитик иярчен җөмлә, аларда бәйләүче чаралар, тыныш билгеләре.<br>Иярченле кушма җөмләләр синонимлыгы | 22 | Иярченле кушма җөмләләрне аера белү, синтаксик анализ ясау |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Иярчен җөмлә һәм аның мәгънә ягыннан төрләре | | |
| | Иярченле кушма җөмләләрне гомумиләштереп кабатлау. | 4 | Иярченле кушма җөмләләрне аера белү, синтаксик анализ ясау |
| 6. | Катлаулы төзелмәләр. Катлаулы кушма җөмлә. Күп тезмәле катлаулы кушма җөмлә. Күп иярченле катлаулы кушма җөмлә. Тиңдәш иярүле күп иярченле катлаулы | 16 | Катлаулы төзелмәләрне аңлата, схемаларын ясый белү |
| | Катлаулы төзелмәләрне кабатлау, синтаксик анализ ясау | 6 | Катлаулы төзелмәләрне аера белү, синтаксик анализ ясау |
| 7. | Тезем. | 2 | Теземне таный белү, синтаксик анализ ясау. |
| 8. | Җөмләнең мәгънәсе һәм төзелеше, интонация һәм тыныш билгеләре | 2 | Җөмләнең мәгънәсе һәм төзелеше, интонация һәм тыныш билгеләренең куелышы |
| 9. | Язма эшләр. Диктантлар. | 31 | |
| 10. | Барлыгы | 105 | |

**Тематик планлаштыру**

Тел һәм тел гыйлеме. -1с.

Үткәннәрне искә төшерү. Фонетика, орфоэпия, орфография, графика, лексикология, фразеология, морфология бүлеген кабатлау. Гади җөмлә синтаксисын кабатлау.-3с.

Диалог һәм монолог.-2с.

Туры һәм кыек сөйләм.-1с.

Алар янында тыныш билгеләре.-2с.

Туры сөйләмне кыек сөйләмгә әйләндерү.-2с.

Туры сөйләмле җөмләгә синтаксик анализ ясау. турында гомуми мәгълүмат.-2с.

Кушма җөмлә турында гомуми төшенчә.-2с.

Тезмә кушма җөмлә. Теркәгечле һәм теркәгечсез тезмә кушма җөмлә. Теркәгечле һәм теркәгечсез тезмә кушма җөмлә, аларда бәйләүче чаралар, тыныш билгеләре.-4с.

Иярченле кушма җөмлә.-1с.

Төзелеше буенча синтетик, аналитик иярчен җөмлә, аларда бәйләүче чаралар, тыныш билгеләре.-4с.

Иярченле кушма җөмләләр синонимлыгы-1с.

Аналитик һәм синтетик иярченле кушма җөмләләрне кабатлау.-1с.

Иярчен җөмлә һәм аның мәгънә ягыннан төрләре.-1с.

Иярчен ия һәм хәбәр җөмләләр Аларның синтетик һәм аналитик төрләре, бәйләүче чаралар һәм тыныш билгеләре; аларга синтаксик анализ ясау.-2с.

Иярчен тәмамлык һәм аергыч җөмләләр. Аларның синтетик һәм аналитик төрләре, бәйләүче чаралар һәм тыныш билгеләре; аларга синтаксик анализ ясау-.2с.

Иярчен вакыт һәм урын җөмләләр. Аларның синтетик һәм аналитик төрләре, бәйләүче чаралар һәм тыныш билгеләре; аларга синтаксик анализ ясау. -2с.

Иярчен рәвеш һәм күләм җөмләләр Аларның синтетик һәм аналитик төрләре, бәйләүче чаралар һәм тыныш билгеләре; аларга синтаксик анализ ясау..-2с.

Иярчен сәбәп һәм максат җөмләләр Аларның синтетик һәм аналитик төрләре, бәйләүче чаралар һәм тыныш билгеләре; аларга синтаксик анализ ясау..-2с.

Иярчен шарт һәм кире җөмләләр Аларның синтетик һәм аналитик төрләре, бәйләүче чаралар һәм тыныш билгеләре; аларга синтаксик анализ ясау..-2с.

Иярчен аныклагыч җөмләләр. Аларның синтетик һәм аналитик төрләре, бәйләүче чаралар һәм тыныш билгеләре; аларга синтаксик анализ ясау.-2с.

Иярченле кушма җөмләләрне гомумиләштереп кабатлау -4с.

Катлаулы төзелмәләртурында төшенчә.-1с.

Күп тезмәле катлаулы кушма җөмлә.-1с.

Күп иярченле катлаулы кушма җөмлә. -1с.

Тиңдәш иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә.-1с.

Тиңдәш түгел иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә.- 2с.

Бер-бер артлы иярүле күп иярченле кушма җөмлә.-2с.

Берничә төр иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә.-2с.

Иярченле кушма җөмләләрне гомумиләштереп кабатлау.-4с.

Катнаш кушма җөмлә.-6с.

Катлаулы төзелмәләрне кабатлау,синтаксик анализ ясау.Аларда бәйләүче чаралар һәм тыныш билгеләре. -6с.

Тезем.Теземнең үзенчәлекләре: санау йомгаклау бүлекләре, интонацион үзенчәлекләре, тыныш билгеләре.-2с.

Җөмләнең мәгънәсе һәм төзелеше, интонация һәм тыныш билгеләре-2с.

Язма эшләр. Диктант.  Изложение. Сочинение. Эш кәгазе. Сочинение, изложениене тикшерү, анализлау.-31с.

# Календарь-тематик план

| | Дәреснең темасы, эчтәлеге | Укучыларның эшчәнлек төре | Үтәлеш<br>Сарман | | Каташ-Каран | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | **Факт** | ***План*** | ***Факт*** | ***план*** |
| 1 | Тел һәм тел гыйлеме. Кереш. | Тел гыйлеменең бүлекләрен искә төшерү. Аларның нәрсә өйрәнүләрен кабатлау. | 02.09 | | 04.09 | |
| 2 | Үткәннәрне искә төшерү. | Бәйләнешле сөйләм; әңгәмәдә катнашу | 04.09 | | 07.09 | |
| 3-<br>4 | Үткәннәрне кабатлау. | Сүз төркемнәрен билгеләү;<br>текстка морфологик анализ ясау. Бәйләнешле сөйләм төзү;<br>Җөмләләр төзү | 06.09<br>09.09 | | 08.09<br>11.09 | |
| 5 | **Диктант “Көз” (кереш диктант)** | Диктант язу; бирем эшләү. | 11.09 | | 14.09 | |
| 6 | Язма эштәге хаталарны төзәтү эше. | Язма эштәге хаталарны төзәтү эшен башкару | 13.09 | | 15.09 | |
| 7-8 | Диалог һәм монолог | Ике яки берничә кешенең үзара сөйләшүе диалог дип аталу. Аерым кешеләрнең диалог эчендәге сүзләренең реплика дип йөртелүе. | 16.09<br>18.09 | | 18.09<br>21.09 | |
| 9 | Туры һәм кыек сөйләм турында гомуми мәгълүмат. | Туры сөйләмне үз сөйләмеңдә файдалану, чит кеше сүзләрен һәр ике юл ( диалог һәм монолог) белән бирү, күнегүләр эшләү | 20.09 | | 22.09 | |
| 10 | Туры сөйләм янында тыныш билгеләре. | Тыңлап аңлау; Дәфтәрдә һәм тактада күнегүләр эшләү. Туры сөйләмгә бәйле тыныш билгеләрен дөрес кую, куелганнарына аңлатма бирү | 23.09 | | 25.09 | |
| 11 | Диалогта тыныш билгеләре | Диалогта һәр репликаның кызыл юлдан һәм сызык куеп язу | 25.09 | | 28.09 | |
| 12-13 | Туры сөйләмне кыек сөйләмгә әйләндерү. | Туры сөйләмне кыек сөйләмгә әйләндерү, күнегүләр эшләү | 27.09<br>30.09 | | 29.09<br>2.10 | |
| 14-15 | Туры сөйләмле җөмләгә синтаксик анализ | Туры сөйләмле җөмләгә синтаксик анализ ясау | 02.10<br>04.10 | | 05.10<br>06.10 | |
| 16-17 | **БСҮ. Иҗади изложение “Синең әниең”** | Укытучы укыганны тыңлау, план төзү, сөйләп карау, караламага язу һәм акка күчерү | 07.10<br>09.10 | | 09.10<br>12.10 | |
| 18 | Изложениене сыйныфта тикшерү, хаталарны төзәтү | Хаталарны анализлау, хаталар өстендә эш эшләү | 11.10 | | 13.10 | |
| 19-20 | Кушма җөмлә турында | Кушма җөмләләрдән тиешенчә файдалану, аларның төрле | 14.10 | | 16.10 | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | гомуми төшенчә. | төрләрен төзү, таләп ителгән төренә мисал китерү | 16.10 | | 19.10 | |
| 21 | Тезмә кушма җөмлә турында гомуми төшенчә. | Текстны өлешчә синтаксик яктан һәм тулы күләмдә гармматик яктан тикшерү | 18.10 | | 20.10 | |
| 22 | Теркәгечле һәм теркәгечсез тезмә кушма җөмлә. | Тыңлап аңлау; кушма җөмләдәге гади җөмләләрне үзара бәйли торган тезүче теркәгечләр: *җыючы, каршы куючы, бүлүче* теркәгечләр белән дәфтәрдә һәм тактада күнегүләр эшләү | 21.10 | | 23.10 | |
| 23 | Теркәгечле тезмә кушма җөмләләрдә тыныш билгеләре. | Дәфтәрдә күнегүләр эшләү; укучылар мөстәкыйль эшлиләр; аерым укучылар индивидуаль эш | 23.10 | | 26.10 | |
| 24 | Теркәгечсез тезмә кушма җөмләләрдә тыныш билгеләре. | Дәфтәрдә күнегүләр эшләү; укучылар мөстәкыйль эшлиләр; аерым укучылар индивидуаль эш | 25.10 | | 27.10 | |
| 25 | Иярченле кушма җөмлә турында гомуми төшенчә. | Тыңлап аңлау. Кушма җөмлә өлешләре арасына тиешле тыныш билгеләрен кую һәм аларны дәлилләү | 28.10 | | 6.11 | |
| 26 | Синтетик иярчен җөмлә. | Тыңлап аңлау. Дәреслектәге күнегүләрне эшләү; таблица тутыру | 6.11 | | 9.11 | |
| 27 | Синтетик иярчен җөмләләр янында тыныш билгеләре. | Синтетик иярчен җөмлә белән баш җөмлә арасына бер генә билге − бары тик өтер генә куелу. | 08.11 | | 10.11 | |
| 28 | Аналитик иярчен җөмләләр. | Тыңлап аңлау. Баш җөмләгә үзенең составында тормый торган чаралар ярдәмендә ияргән җөмләләрнең аналитик иярчен җөмлә дип аталуы. Аналитик иярчен җөмләләрнең баш җөмләгә мөнәсәбәтле сүзләр, теркәгеч һәм теркәгеч сүзләр, көттерү интонациясе белән бәйләнүе. | 11.11 | | 13.11 | |
| 29 | Аналитик иярчен җөмләләр янында тыныш билгеләре. | Карточкалар белән эшләү. Аналитик иярчен җөмләләр янында тыныш билгеләрен кую | 13.11 | | 16.11 | |
| 30-31 | **БСҮ. Контроль изложение “Бикмүш бабай”** | Укытучы укыганны тыңлау, план төзү, сөйләп карау, караламага язу һәм акка күчерү. | 15.11<br>18.11 | | 17.11<br>20.11 | |
| 32 | Язма эштәге хаталарны төзәтү эше. | Хаталарны төзәтү эшен башкару | 20.11 | | 23.11 | |
| 33 | Аналитик һәм синтетик иярченле кушма җөмләләрне кабатлау. | Кагыйдәләрне искә төшерү; ныгыту күнегүләре эшләү. | 22.11 | | 24.11 | |
| 34 | Иярченле кушма җөмләләр синонимлыгы. | Синонимик иярченле кушма җөмләләрдә мәгънә, нигездә бер үк булуы, иярчен җөмләләрнең дә бер үк мәгънәле сорауга җавап бирүләре. | 25.11 | | 27.11 | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 35 | **Диктант “Кышкы юлда”** | Диктант язу, грамматик биремнәрне эшләү. | 27.11 | | 30.11 | |
| 36 | Язма эштәге хаталарны төзәтү эше. | Диктанттагы хаталарны төзәтү, узган материалны кабат искә төшерү, ныгыту. | 29.11 | | 1.12 | |
| 37 | Иярчен җөмлә һәм аның мәгънә ягыннан төрләре. | Иярчен җөмләне табу. Дәфтәрдә һәм тактада күнегүләр эшләү. | 02.12 | | 4.12 | |
| 38-39 | Иярчен ия һәм хәбәр җөмләләр. | Дәфтәрдә һәм тактада күнегүләр эшләү. | 04.12<br>06.12 | | 7.12<br>08.12 | |
| 40-41 | Иярчен тәмамлык һәм иярчен аергыч җөмләләр. | Дәфтәрдә һәм тактада күнегүләр эшләү. | 09.12<br>11.12 | | 11.12<br>14.12 | |
| 42 | **Контроль диктант «Кышкы ял вакытында»** | Диктант язу, грамматик биремнәрне эшләү. | 13.12 | | 15.12 | |
| 43 | Язма эштәге хаталарны төзәтү эше. | Диктанттагы хаталарны төзәтү, узган материалны кабат искә төшерү, ныгыту. | 16.12 | | 18.12 | |
| 44-45 | Иярчен вакыт һәм иярчен урын җөмләләр. | Дәреслек материалы белән танышу; дәфтәрдә күнегүләр эшләү; мөстәкыйль эшләү. Схемалар төзү | 18.12<br>20.12 | | 21.12<br>22.12 | |
| 46 | Беркетмә язарга өйрәнү. | Эш кәгазьләре үрнәкләре белән танышу, план буенча мөстәкыйль беркетмә язу | 23.12 | | 8.01 | |
| 47-48 | Иярчен рәвеш һәм иярчен күләм җөмләләр. | Дәреслек материалы белән танышу; дәфтәрдә күнегүләр эшләү | 8.12<br>10.01 | | 11.01<br>12.01 | |
| 49-50 | **Бәйләнешле сөйләм үстерү. Изложение “Дуслар”** | Укытучы укыганны тыңлау, план төзү, сөйләп карау, караламага язу һәм акка күчерү. | 13.01<br>15.01 | | 15.01<br>18.01 | |
| 51 | Язма эштәге хаталарны төзәтү эше. | Хаталарны төзәтү эшен башкару | 17.01 | | 19.01 | |
| 52-53 | Иярчен сәбәп һәм иярчен максат җөмләләр. | Дәреслек материалы белән танышу; дәфтәрдә күнегүләр эшләү | 20.01<br>22.01 | | 22.01<br>25.01 | |
| 54-55 | **Бәйләнешле сөйләм үстерү. Сочинение-хөкем йөртү**. | Әңгәмә, сорауларга җавап бирү, үзара сөйләшү; бирелгән план буенча инша язу. | 24.01<br>27.01 | | 26.01<br>29.01 | |
| 56 | Сочинениене сыйныфта тикшерү. Хаталарны анализлау, төзәтү эше. | Хаталарны төзәтү эшен башкару | 29.01 | | 1.02 | |
| 57-58 | Иярчен шарт һәм иярчен кире җөмләләр. | Җөмләләр төзү, дәфтәрдә күнегүләр эшләү | 31.01<br>03.02 | | 2.02<br>5.02 | |
| 59-60 | Иярчен аныклагыч җөмләләр | Җөмләләр төзү, дәфтәрдә күнегүләр эшләү | 05.02 | | 08.02 | |
| 61-64 | Иярченле кушма җөмләләрне гомумиләштереп кабатлау. | Бүлек буенча өйрәнелгәннәрне ныгыту. Кушма җөмләләрне схемаларда күрсәтү буенча күнегүләр эшләү. Тыныш билгеләрен | 07.02<br>10.02 | | 09.02<br>12.02 | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | мөстәкыйль кую. | 12.02<br>14.02 | | 15.02<br>16.02 | |
| 65 | **Диктант(тикшерү диктанты)** | Диктант язу, грамматик биремнәрне эшләү. | 17.02 | | 19.02 | |
| 66 | Хаталарны анализлау, төзәтү эше. | Диктанттагы хаталарны төзәтү, узган материалны кабат искә төшерү, ныгыту. | 19.02 | | 22.02 | |
| 67 | Катлаулы төзелмәләр турында төшенчә | Тыңлап аңлау, тактада һәм дәфтәрдә күнегүләр эшләү. Схемалар төзү. Схемалар төзү | 21.02 | | 23.02 | |
| 68 | Күп тезмәле катлаулы төзелмә | тактада һәм дәфтәрдә күнегүләр эшләү; аерым укучыларга индивидуаль эш. | 24.02 | | 26.02 | |
| 69 | Күп иярченле кушма җөмлә турында төшенчә. | Яңа материал белән танышу, күнегүләр эшләү. Схемалар төзү | 26.02 | | 1.03 | |
| 70 | Тиңдәш ияргүле күп иярченле кушма җөмлә. | Дәреслек материалы белән танышу; дәфтәрдә күнегүләр эшләү | 28.02 | | 2.03 | |
| 71 | **Диктант (тикшерү диктанты)** | Диктант язу, грамматик биремнәрне эшләү. | 03.03 | | 05.03 | |
| 72-73 | Тиңдәш түгел ияргүле күп иярченле кушма җөмлә. | Текст белән эшләү, күнегүләр эшләү, сорауларга җавап бирү. Схемалар төзү | 05.03<br>07.03 | | 08.03<br>09.03 | |
| 74-75 | Бер-бер артлы ияргүле күп иярченле кушма җөмлә. | Текст белән эшләү, күнегүләр эшләү, сорауларга җавап бирү, җөмләләр төзү<br>Схемалар төзү | 10.03<br>12.03 | | 12.03<br>15.03 | |
| 76-77 | Берничә төр ияргүле күп иярченле кушма җөмлә. | Текст белән эшләү, күнегүләр эшләү, сорауларга җавап бирү, җөмләләр төзү<br>Схемалар төзү | 14.03<br>17.03 | | 16.03<br>19.03 | |
| 78-79 | **Бәйләнешле сөйләм үстерү. Контроль изложение<br>” Хезмәткә – хөрмәт”** | Укытучы укыганны тыңлау, план төзү, сөйләп карау, караламага язу һәм акка күчерү. | 19.03<br>21.03 | | 22.03<br>23.03 | |
| 80 | Хаталарны анализлау, төзәтү эше. | Хаталарны төзәтү эшен башкару | 24.03 | | 5.04 | |
| 81-85 | Иярченле кушма җөмләләрне | Алдагы дәрес материалын искә төшерү, мөстәкыйль эш эшләү | 04.04 | | 06.04 | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | гомумиләштереп кабатлау. | | 07.04<br>09.04<br>11.04 | | 09.04<br>12.04<br>13.04 | |
| 86-87 | **Контроль сочинение (сыйфатлама)** | Сочинениегә материал туплау, аларны эзлекле тәртипкә китерү, язу, акка күчерү. | 14.04<br>16.04 | | 16.04<br>19.04 | |
| 88 | Сочинениене бергәләп тикшерү, хаталарны төзәтү | Сочинениедәге хаталарны анализлау, төзәтү | 18.04 | | 20.04 | |
| 89-94 | Катнаш кушма җөмлә. | Текст белән эшләү, күнегүләр эшләү.<br>Схемалар төзү | 21.04<br>23.04<br>25.04<br>28.04<br>30.04<br>02.05 | | 23.04<br>26.04<br>27.04<br>30.04<br>3.05<br>04.05 | |
| 95-100 | Катлаулы төзелмәләрне кабатлау, синтаксик анализ ясау | Бүлек буенча өйрәнелгәннәрне ныгыту. Кушма җөмләләрне схемаларда күрсәтү, синтаксик анализ ясау | 05.05<br>07.05<br>09.05<br>12.05<br>14.05<br>16.05 | | 07.05<br>10.05<br>11.05<br>14.05<br>17.05<br>18.05 | |
| 101-102 | Тезем. | Тиңдәш кисәкләре яки тиңдәш җөмләләре күп булу аркасында бик нык җәенкеләндерелгән гади яки кушма җөмләләрнең тезем дип аталулары. Тыныш билгеләренең куелышы | 19.05<br>21.05 | | 21.05<br>24.05 | |
| 103 | **Контроль диктант “Беренче яңгыр”** | Грамоталылык дәрәҗәсен тикшерү максатында. | 23.05 | | 25.05 | |
| 104-105 | Җөмләнең мәгънәсе һәм төзелеше, интонация һәм тыныш билгеләре | Аңлап тыңлау. Текст белән эшләү, күнегүләр эшләү, сорауларга җавап бирү. | 26.05<br>28.05 | | 28.05<br>31.05 | |

## Гомумбелем күнекмәләрен бәяләүнең критерийлары һәм нормалары

**<u>Язма эшләрнең күләме һәм аларны бәяләү:</u>**

Сүзлек диктантының күләме –15-20 сүз

**Сүзлек диктантын бәяләү**

1. Пөхтә язылган, хатасы булмаган эшкә “5” ле куела.
2. Бер орфографик хаталы эшкә “4” ле куела.
3. Өч орфографик хаталы эшкә “3” ле куела.
4. Биш орфографик хаталы эшкә “2” ле куела.

Контроль диктант текстының күләме - ел башында 100 сүз, ел ахырында - 110 сүз

**Контроль диктантны бәяләү:**

1. Эш пөхтә башкарылса, хатасы булмаган эшкә “5” ле куела. (Бер – орфографик, ике пунктуацион хата булырга мөмкин.)
2. Ике орфографик, ике пунктуацион яки бер орфографик, дүрт пунктуацион хаталы эшкә “4” куела.
3. Дүрт орфографик, дүрт пунктуацион яки өч орфографик, алты пунктуацион хаталы эшкә “3” куела.
4. Алты орфографик, биш пунктуацион яки биш орфографик, сигез пунктуацион хаталы эшкә “2” куела.

Изложение текстының күләме ел башында 150-170 сүз (110-120- язма күләме)

**Изложениене бәяләү**

1. Тема тулысынча ачылган, фактик һәм техник хаталары булмаган, стиль бердәмлеге сакланган эшкә «5»ле куела. (Берорфографик, икепунктуацион яки ике грамматик хатасыбулырга мөмкин.)
2. Текстның эчтәлеге темага нигездә туры килсә, фикерне белдерүдә зур булмаган ялгышлыклар җибәрелсә, бер-ике фактик, бер-ике техник хатасы булса, ике орфографик, ике-өч пунктуацион, бер грамматик хатасы булган эшкә «4» ле куела.
3. Язмада эчтәлек эзлекле бирелмәсә, стиль бердәмлеге сакланмаса, өч фактик, ике-өч техник хатасы булса, өч орфографик, дүрт пунктуацион, ике грамматик хатасы булган эшкә «3» ле куела.
4. Эзлеклелек, стиль бердәмлеге сакланмаса, язма эш планга туры килмәсә, фактик һәм техник хаталары күп булса, орфографик хаталарның саны дүрттән, пунктуацион хаталарның саны биштән, грамматик хаталар саны өчтән артса, «2» ле куела.

Сочинениенең күләме һәм аны бәяләү

Иҗади эшнең бер төре буларак, сочинение — укучының язма рәвештә үти торган эше. Ул бәйләнешле сөйләм үстерү күнекмәләре булдыруда зур әһәмияткә ия. Әдәби (хикәяләү, очерк, истәлек, хат, рецензия һ. б.), әдәби-иҗади, өйрәтү характерындагы, ирекле, рәсемнәр нигезендә үткәрелә торган һәм контроль сочинениеләр була.

**Сочинениене бәяләү**

1. Язманың эчтәлеге темага тулысынча туры килсә, фактик ялгышлары булмаса, бай телдә, образлы итеп язылса, стиль бердәмлеге сакланса, «5»ле куела. (Бер орфографик яисә ике пунктуацион (грамматик) хата булырга мөмкин)
2. Язманың эчтәлеге нигездә темага туры килсә, хикәяләүдә зур булмаган ялгышлыклар күзәтелсә, бер-ике фактик хата җибәрелсә, теле бай, стиль ягы камил булып, ике орфографик, өч пунктуацион (грамматик) яисә бер-ике сөйләм ялгышы булса, «4»ле куела.

3. Эчтәлекне бирүдә җитди ялгышлар, аерым фактик төгәлсезлекләр булса, хикәяләүдә эзлеклелек югалса, сүзлек байлыгы ярлы булса, стиль бердәмлеге дөрес сакланмаган җөмләләр очраса, өч орфографик, дүрт пунктуацион (грамматик) яисә өч-дүрт сөйләм хатасы булса, «3»ле куела.
4. Язма темага туры килмичә, фактик төгәлсезлекләр күп булып, план нигезендә язылмаса, сүзлек байлыгы бик ярлы булса, текст кыска һәм бер типтагы җөмләләрдән торып, сүзләр дөрес кулланылмаса, стиль бердәмлеге сакланмаса, биш орфографик, сигез пунктуацион (грамматик) яисә дүрт—алты сөйләм хатасы булса, «2»ле куела.

**Тестны бәяләү**

1.Тестның 76-100% дөрес башкарылган эшкә “5”ле куела.
2. Тестның 61-75% дөрес башкарылган эшкә “4”ле куела.
3.Тестның 51-60% дөрес башкарылган эшкә “3”ле куела.
4.Тестның 0-50% дөрес башкарылган эшкә “2”ле куела.

**Мөстәкыйль эшне бәяләү**

1. Мөстәкыйль эшнең **7**5-100% дөрес башкарылган эшкә “5”ле куела.
2. Мөстәкыйль эшнең60-74% дөрес башкарылган эшкә “4”ле куела.
3.Мөстәкыйль эшнең 41-59% дөрес башкарылган эшкә “3”ле куела.
4.Мөстәкыйль эшнең 0-40% дөрес башкарылган эшкә “2”ле куела.

# Диктантлар

## Диктан №1
## Көз

Төрле буяулары белән алтын көз килә. Көндез җылы җәйдән аерма юк диярсең: кояш кыздыра,күк йөзе зәңгәрләнеп тора. Иртән һәм кичен көннәр салкынча. Агач яфраклары,аз гына кагылуга, төрле төстәге күбәләкләр кебек, җиргә сибелә башлыйлар. Урманнар сирәгәя башлый. Бу чорны халыкта “Әбиләр чуагы” дип йөртәләр. Бары тик чыршылар гына,яшел туннарын кигән килеш,кышка керергә җыеналар. Җәйнең тырыш эшчеләре - бал кортлары - кышка әзерлекләрен тәмамлап киләләр. Җәнлекләр, хайванннар һәм кошлар өчен әле җирдә азык күп, шуңа күрәдер, аларның кәефләре яхшы.

Алтын көз үзенең муллыгы белән күңелгә якын. Өлгергән җиләк-җимеш, яшелчә, иген әле җыелып бетмәгән. Һәркем шул уңышны җыю белән мәшгуль. (100 сүз)

**Диктан №2**
**Кышкы юлда.**

Алдагы көндә сине ни көткәнне бервакытта да анык белә алмыйсың. Рушад та урман буендагы юлдан билгесезлеккә атлый.

Әнә кар диңгезе күк белән тоташкан урынннан тәгәрәп кенә кызгылт-сары кояш чыгып килә. Кояш җир йөзенә һәр көн үзенчә чыга, чөнки уз үзенең төсләрен кабатларга яратмый. Бүген ул каты бураннардан соң беренче мәртәбә күренә, шуңадыр кыяфәте арган, йончыган.

Иртәнге салкынча җил, иренеп кенә, басу өстеннән кар сыпырып йөртә. Ул кояш чыгуны тереклек дөньясына хәбәр итә. Кар дәрьясы өстендәге салкынча тыгыз һава аркылы узган кояш нурлары зәгыйфь саргылт төскә кергәннәр. Кояш тирәсендә ниндидер бөҗра. Ул бөҗра офыктагы аксыл томанга асып куелган кебек. Җил кар өстендә имән яфракларын шудыртып йөртә. Имән яфраклары быел да коелып бетмәгән икән. Агач яфрагы коелып бетмәсә, елны авыр килә диләр. Сугыш беткәч, тагы нинди авырлык килер икән халыкка? Хәер, ел авыр, бик авыр. Тик хәзер үлем, кан кою гына юк. Шул уйлар белән Рушад кар диңгезе өстеннән атлый. Башында бер уй һич тынгылык бирми: алданиләр көтә аны?

*(158 сүз) М.Мәһдиев*

---

**Диктан №3**
**Кышкы ял вакытында**

Кышкы каникулда безне ел саен спорт базасына алып баралар. Безне шефка алган завод базасы ул, шәһәрдән читкә салынган. Әй рәхәт тә була соң урманда чаңгы шуулары! Таулардан ыжгыртып чабып төшүләре дисеңме, егылып киткәндә, баш белән карга кадалулар дисеңме, агач араларыннан борыла-борыла төшкәндә, чаңгы астыннан кар бураннары уйнап калулар дисеңме!Чаңгы шуа белмәгән кешегә аның рәхәтен аңлатып торып булмый инде. Ә сезнең кышкы урманда тукран тукылдатканны тыңлап торганыгыз бармы?Яисә песнәк сайрганны ишеткәнегез? Ә саесканның койрыгы ник шул тамаша озын булганны беләсезме?Анысын мин дә белмим.

Каникуллар җиткәндә, урмандагы спорт базасына барыр көнне без зарыгып көтә башладык.Ай, көткәндә вакыт акрын гына уза да соң.Андый чак әллә көннәр юри терәлеп торалар инде?Шулай да барыр сәгатьләр җитте.Автобуска утыртып, безне Аккош күле ягына урманга чаптыртып алып киттеләр. Базага без әле иртүк барып җиттек.Чаңгылар алып шуарга чыгып киттек. Шәһәрдә кар пычрак, ә монда ап-ак, очкынланып, җем-җем итеп ята.

(И.Газидан ) (147 сүз)

---

**Диктан №4**
**Колын**

Җәй башында безнең җирән кашка колын алып кайтты.

Хәзер мин, бүтән уеннарымны онытып, көнозын колын тирәсендә бөтерелә башладым. Иртән торуга иң беренче куанычым шул: ипи йомшагы эләктерәм дә колын янына чыгам. Баштарак ул, мин керүгә, тизрәк анасына барып сыена иде. Тора-бара ияләнде. Мин дәшкәч, колакларын торгызып, борылып карый торган булды. Бераздан, матур борын тишекләрен селкеткәләп, ипи исни башлады. Аннары көл төсле зәңгәрсу-соры, хәтфә кисәге шикелле йомшак реннәре белән уч төбннән ипи сыныклары эләктереп алырга өйрәнде.

Өммикамал апа зәңгәр сатиннан муенса тегеп биргәч, колынның муенына кечкенә генә шөлдер тагып җибәрдек. Колын башын селкеткән саен, ул гаҗәп сөйкемле тавышлар чыгара, әйтерсең, чың-чың итеп, берьюлы әллә ни тикле көмеш тәңкә коела. (110 сүз) Г.Бәширов

---

**Диктан №5**

**Чишмә янында**

Серле тынлык белән ак яктылык кына эленеп тора иде тирә-юньдә. Рәхимҗан шулкадәр бәхетле һәм шат иде: ул җир белән күк, болыт белән көрт аермасын онытты.

Кинәт каядыр янәшәдә генә колагына серле аваз чалынгандай булды. Челтерәү авазы якыная төшкәч кенә, үзенең җирдә булуын, инеш буйлап чишмәгә баруын төшенде.

Җылы пар бөркеп, челтерәп агып яткан чишмәне күргәч, таң калды егет. Гаҗәпләнмәслек тә түгел: бөтен дөнья – урам һәм тыкрыклар, инеш һәм су буйлары кар астында йомылып яткан бермәлдә чишмә күмелмичә калган. Нурлы аланлылар үзен күптән оныткан булуга карамастан, чишмә тирән кар катламын ярып чыккан: тибеп тора.

Җылынып киткәндәй булды егет, чөнки шаулап аккан салкын чишмә суыннан җылы пар бөркелә иде. Егет, билдән карга батып, үргә чана тартып менгәндә дә, урамнардан үткәндә дә, шул җылылык аны озата барды.

Иртәгесен тагы су буена төште Рәхимҗан. Ак кар өстендә күзгә күренер-күренмәс кенә зәңгәрсу рәшә йөгерә. Никадәр матурлык монда!

(143 сүз) Р.Мөхәммәдиев

---

**Диктан №5**

**Беренче яңгыр**

Язның беренче яңгыры кинәт килде. Таң беленер-беленмәстә, көньяк-көнбатыштан кабарып чыккан болыт ерактан торып бер-ике тапкыр гөлдерәп тавыш бирде дә, әкияттәге Каф тавыдай калкып, ярты күк йөзен томалады. Тау артыннан кояш күтәрелә башлауга, ул, киң кара-кучкыл канаты белән көнне тагын да караңгылатып, бөтен күк йөзен каплады.

Күп тә үтмәде, салкынча яңгыр җиле Карамалы урамнарында өермә кузгатты. Кар сулары киткәннән бирле битен-күзен бер тапкыр да юмаган агачлар яңгыр килгәнне сизеп шаулашып куйдылар.

Бераздан, урам-тыкрыклардагы чүп-чарны бөтереп, өермә җиле узды. Нава, афәт көткәндәй, берара тынып торды. Менә шунда, һәммә нәрсә, барча тереклек инде тагын ни булыр дип көткәндә, күк йөзен икегә ярып, яшен яшьнәде, һәммә җан иясе сискәнеп куйды, чөнки яшен артыннан чытырдап күк күкрәде. Беренче курку үтеп, күк йөзе тагын дөбердәгәч, эре-эре яңгыр тамгалый башлады, ә берничә минуттан чиләкләп коярга тотынды.

Яңгыр әллә ни озак яумады сыман, әмма юл-сукмакларга су җыелды; шаулап, гөрләвекләр агып китте. (143 сүз)

*М. Хәбибуллин*

**Бирем**

Соңгы җөмләнең төрен билгеләргә һәм тыныш билгеләрен аңлатырга.

# Изложениеләр

## Изложение №1
## Синең әниең

Равил сугыш елларында туды. Ашарга такы–токы, өйләре суык була торган иде. Сәрби апа салкын урынга башлап үзе ятып, Равилне үзенең өстенә сала, урынны шулай җылытканнан соңгына Равилне үз янына урынга яткыра иде. Үзе авырса авырды, Равилне авырулардан саклады. Үзе ач торса торды, Равилне ач итмәскә тырышты. Сугыш беткәч, Сәрби апаны Казан янындагы санаторийга дәваланырга җибәрделәр, аңарда ревматизм авыруы башланган иде. Ара әллә ни ерак түгел, Сәрби апа кай көннәрне улы Равил янына шәһәргә кайта иде. Ул елларда әле хәзерге кебек муллык юк. Өйдә улыма ак булка эләкми, дип уйласа, ананың тамагыннан үтми, шуңа күрә ул, чәй янына бирелә торган булкаларны җыеп, Равилгә алып кайтып бирә иде.

Равил мәктәпне тәмамлап, заводка өйрәнчек булып эшкә кергәч, беренче тапкыр хезмәт хакы алды. Бу бик аз акча иде әле. Шушы ике бөртек акчаны зур итеп әнисенә алып кайтып биргәннән соң, Сәрби апаның башы күкләргә тиде. Аның улы Равил акча эшли башлады бит! Әле кайчан гына Равил беренче тәпи баскан һәм шушы куанычтан “гый!” дип дип көлеп җибәргән иде. Ә бүген инде ул заводтан әнисенә беренче хезмәт хакын алып кайтып бирде. И бу дөньялар! Шундый тиз үтә ләбаса! Кичә генә биләүдә яткан бала бүген инде икмәклек акча эшли башлады. Сәрби апаның куанычын күрсәгез иде! Юк,бу куанычны үзе ана булган кеше генә аңласа аңлар!

Равилне быел армиягә алдылар. Ул әнкәсенә язган хатларында туып үскән шәһәрен, уйнап йөргән урамнарын, өй каршында үскән тирәк агачларын сагынуын яза: “Әни, - дигән ул күптән түгел язган хатында.- Мин ясап элгән сыерчык оясына быел да сыерчыклар оялар микән? Ояласалар, һәр елдагы кебек, канат җилпеп куакта сайрасалар, син миңа язып җибәр, яме? Марсельгә әйтеп кара әле, фотога төшереп җибәрмәс микән? Барыгызны да бик-бик сагындым!”.

Әни, Туган ил... Һәркемнең күңеле өчен иң изге, иң газиз нәрсәләр алар. Балага үз әнкәсеннән дә күркәмрәк, кадерлерәк җан булмаган кебек, егет кешегә, ир кешегә үз иленнән дә матуррак, якынрак ил юк. Әни һәм туган- үскән җир- сине карап үстерүче, сине кеше итүче, сине сагынучы һәм сагындыручы шулар. *(323 сүз) ( И. Газидан)*

## Изложение №2
## Бикмүш бабай

Соңгы маякны сүндерергә килгәндә, кызарып чыккан кояшның беренче алтын нурлары тын Идел өстенә җәелде. Нәкъ шул чакта Илсөяр көн дә шушы вакытта ишетә торган ягымлы иркә тавыш ишетте:

— Илсөяр!..
— ... Әнә бабаң да торган, кызым.
— Әйбәт йокладыңмы, бабай?
— Аю кебек, кызым.

Илсөяр бабасының муенына сарылды.

Бикмүш бабай ─ Мәрдән абзыйның атасы. Карт инде ул, җитмешкә җитеп килә. Ул шул гомеренең күп өлешен Урал шахталарында күмер чабып үткәрде. Картаеп эшкә ярамый башлагач, аны хуҗалары куып чыгардылар. Бикмүш бабай, җиде-сигез йөз чакрымнан җәяүләп, үзенең туган авылына ─ улы Мәрдән янына кайтырга чыкты. Аның ашарына юк иде. Юлда очраган авылларга туктап, хәер сораша-сораша кайтты.

Ярты юлга җиткәндә, Бикмүш бабайның кинәт кенә бер канаты сынды: кырык ел буена бергә гомер иткән карчыгы үлеп калды. Карчыгы үлгәч, Бикмүш бабай өчен дөньяның кызыгы бөтенләй бетте. Аның аяклары тагын да авыррак атлый башладылар.

Газаплы кара көннәрен бизәп торган гомер юлдашы исенә төшкән саен, Бикмүш сабыйларча үксеп елады.

Шулай кайта торгач, ул үзе иген игеп үскән таныш кырларга аяк басты. Алпавыт камчысы, нужа чыбыркысы... Ә шулай да Туган ил ─ Туган ил шул! Дәртләнеп китте ул.

Ул басу капкасын керде һәм чатны борылды. Монда аның соңгы канатын да сындырып ташладылар. Авылда беренче очраган кеше ─ көтүче карт ─ Мәрдәннең күптән инде авылдан куылуын, аның башыннан үткән фаҗигале хәлләрне сөйләп бирде.

Бикмүш бабай алабута, кычыткан баскан ата-баба нигезенә йөзен куеп яшь түгә дә, тагын хәер сораша- сораша, улын эзләп чыгып китә. Йөри-йөри, менә шушы Агыйдел буйларына килеп чыга. Шул көннән башлап, Мәрдән абзый, Бикмүш бабай, Илсөяр ─ өчәү бергә яши башлыйлар.

*(Г. Гобәй) (252 сүз*)

**Изложение №3**
**Дуслар**

Без, бер авылда туып, бер суны эчеп үскән булсак та, төрлебез төрле урамнарда, төрле өйләрдә торгангамы, холыкларыбыз, һөнәрләребез бик төрлечә иде.

Фазыйлдан башка безнең компания әллә кайчан таралган булыр иде. Кайбер вакыт юк-бар өчен талашып китәбез. Бәргәләшеп алган чаклар да була. Менә мондый заманнарда Фазыйл әллә кайдан акыл таба, кызык сүз әйтә, яңа уен чыгара да, әле биш минут элек кенә бугазга бугаз килгән малайлар, гөрләшеп, кочакланышып, яңадан уйнарга тотыналар. Мин бөтен компаниягә балык тотуларда, урманга, тауга, җиләккә йөрүләрдә командир булдым. Минсез мондый эшләр башланмый, башласалар да, очлап чыгара алмыйлар.

Зариф карт улы Гыйлаҗи сугыш-талаш вакытларында безне коткара. ...Без, үзара бик артык якынаеп киткәч, авыл малайлары өстеннән бөтенләй башлык кебек булдык. Теләсә язгы ат чаптыруларда, теләсә базарларда, теләсә башка уеннарда — без һаман үзебез теләгәнчә алып барабыз. Моңа башкаларның эчләре поша. Шуңа күрә атна саен диярлек бәрелешләр була. Менә мондый вакытларда Гыйлаҗи булмаса, без, лачыннан качкан чәүкәләр кебек, таркалабыз да бетәбез... Тик ул гына үзенең курку белмәс йөрәге, таза калын беләкләре белән безнең дошманнарыбызга каршы тора алуыбызга сәбәп була.

Аның өстенә тагын Гыйләҗи бөтен авыл малайлары арасында бөрдәнбер балта остасы санала. Яз килсә, ул безгә менә дигән кймәләр ясап бирә. Кошлар килеп җиткәндә, безнең һәркайсыбызның кечкенә өй кебек матур, җыйнак итеп ясалган сыерчык ояларыбыз әзерләнеп,

биек киртәләр башына утыртып куелган була. Боларны да ул ясый.

Җиләк җитсә, кечкенә-кечкенә тубаллар, көз керсә, авылның бер башыннан икенче башына ишеттерерлек итеп яңгвратып суга торган биек, текә какмалар – болар һәммәсе шул атасына охшап туган Гыйләҗи кулыннан ясалып килә.

Галине әйтәсе дә юк... Һәммәсен Гали ташый. Акча дигәнең аларда өзелми. Конфетлар, клиндерлар, прәннекләр белән аның үзенең тешләре череп беткән. Без дә болардан ара-тирә авыз итәргә кире тормыйбыз.

Шаһбаз иң соң килеп кушылса да, ул тиз арада безнең компаниянең үзәге булып алды.

Бер җиргә уенга барасымы, җиләккә, балыкка бару өчен җыярга кирәкме, яки берәребезне кыйный башлаганнармы — янында Шаһбаз булса, бер дә аптырамыйсың! Ул, ике бармагын тешләренә куеп, берничә сызгырып җибәрә икән, безнекеләр хәзер сизеп алалар да, кайда, нинди эштә булса да, чабып килеп җитәләр. Әйтерсең әкияттәге җеннәр инде! Бу сызгыруда авылда гына түгел, тирә-якта да аның тиңдәше юк, диләр. Йөгерүдә, суда йөзүдә дә аңа чыккан кеше юк. Без инде аның сызгыруыннан нәрсә әйтергә теләгәнен тел белән сөйләп биргән, сүз белән кычкырган кебек аңлыйбыз. *(303 сүз)* *Г.Ибраһимовтан*

**Изложение №4**

**Хезмәткә – хөрмәт.**

Икмәк!

Бу сүз – ана исеме белән янәшә торырлык олы сүз. Икмәк турында бер генә көн уйламый калган кеше бармы икән дөньяда?!

Чыннан да, шулкадәр мактаулы, олы, шулкадәр изге саналган, йортыбызга бәхет алып килгән икмәкне ихтирам итәбезме без?

Беркөнне бер танышым белән иртәнге тыныч, бик матур вакытта Аккош күле янындагы яшел алан аша сузылган сукмак буйлап сөйләшә-сөйләшә кайтып киләбез. Юлда анда-монда ташланган икмәк телемнәрен күрдек. Хәтта бер агач төбендә бер бөтен икмәк аунап ята иде.

Үзебез дә сизмәстән, шул икмәккә карап туктадык та телсез калган кебек булдык. Шулай рәхимсез ташлап калдырылган шушы изге ипи өчен безгә дә бик уңайсыз булып тоелды. Дөресен әйткәндә, без оялдык. Кемнеңдер бу мәрхәмәтсезлеге өчен без дә җаваплы идек шикелле.

Бу икмәкне кем ташлаган? Ул рәхимсез бәндәнең исеме ничек? Имзасын язмаган, тамгасын да калдырмаган. Бар, белеп кара. Бәлки, ул, бу минутларада кибеттән тагын икмәк алып, өенә тыныч кына кайтып килеш торгандыр.

Менә шушы кырда трактор җир сөргән, орлык чәчкән, ә хәзер комбайн урып, җыеп, сугып бара. Бу биек арышлар, бу куе бодайлар син әйткәнчә генә усмиләр шул. Бу җирләргә яңгыр гына яумаган, монда игенченең маңгай тирләре дә тамган. Ә кайбер вакытларда, бәлки, бу кырларны кешенең күз яшьләре дә чылаткандыр. Игенче язып, көзен яңгыр астында калмаганмы? Үзәк өзгеч җилләрдә сызмаганмы? Монда йокысыз төннәр дә бар, җәфалы көннәр дә бар. Кибеттән икмәк алганда, шул хәлләр исеңә төшсә, бәлки, син ул кешенең хезмәтен аяк астына ташламас идең. Әгәр уйлабрак карасаң, бу җир туфрагы инде мең еллар буена кулдан кулга күчеп килгән. Бу җирләрдә кояш җылысы гына түгел, йөрәк җылысы да калган.

Шулай да беркая да язылмаган закон бар. Икмәккә – ихтирам, кешегә – мәхәббәт! Бу сүзләр йөрәктә яши. Шуңа күрә дә алар тормыш законы дип аталырга хаклы. Бу законны үтәү – һәркемнең изге бурычы.

Икмәк – кешенең бөек хезмәте дә, горурлыгы да. Син бу хакта да оныткансың, гражданин, беркайчан да онытма!

**Уку-укыту өчен методик кулланмалар (белем бирү чыганаклары)**

1. Изложениеләр җыентыгы: Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең 5-11нче сыйныфлары өчен/ Хәбибуллина З.Н., Гыйләҗев И.Г. – Казан: Мәгариф, 2003.
2. 5-11нче сыйныфлар өчен диктантлар җыентыгы: Татар урта гомуми белем мәктәпләре укытучыларына кулланма/ Төз.-авт. З.Н.Хәбибуллина, Г.Ш.Нәбиуллина. – Казан: Мәгариф, 2001.
3. Харисова Ч.М. Татар теле. Анализ үрнәкләре: Югары сыйныф укучылары, абитуриентлар, укытучылар өчен ярдәмлек/ Ч.М.Харисова. – Казан: Мәгариф, 2009.
4. Сафиуллина Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле: Күнегүләр: Югары һәм урта уку йортлары өчен/ Ф.С.Сафиуллина. - Казан, Мәгариф, 2002.
**5. Сүзлекләр:**
Татар теленнән аңлатмалы сүзлек (3 томда)
Татар теленнән орфографик сүзлеге, 2010.

**6. Интернет ресурслар:** mon.tatar.ru, edu.tatar.ru (“Сообщества” бүлеге), infourok.ru, tatpoisk.net, belem.ru, nsportal.ru, gzalilova.ru.